**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЮТАЗИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АБСАЛЯМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
423957, Республика Татарстан,
Ютазинский район, с.Абсалямово,
ул. Молодежная д.2
E-mail: Absal.Utz@tatar.ru
тел./факс: 4-26-79

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
423957, Татарстан Республикасы,
Ютазы районы, Әбсәләм авылы,
Яшьләр урамы, 2
E-mail: Absal.Utz@tatar.ru
тел./факс: 4-26-79

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 8** **«9»февраля 2026 года**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитетының 2025 елның 29 апрелендәге 10 санлы
«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Әбсәләм авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең балалар уен һәм спорт мәйданчыкларында балалар мәйданчыкларын, уен һәм спорт җиһазларын тоту һәм эксплуатацияләү, җиһазларның техник торышын һәм имин эксплуатациясен тикшереп торуны оештыру кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон», 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 210-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитетының 2025 елның 29 апрелендәге 10 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Әбсәләм авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең балалар уен һәм спорт мәйданчыкларында балалар мәйданчыкларын, уен һәм спорт җиһазларын тоту һәм эксплуатацияләү, җиһазларның техник торышын һәм имин эксплуатациясен тикшереп торуны оештыру кагыйдәләре»нә түбәндәге үзгәреш кертергә:
1.1. Кагыйдәләрнең 4.2 пунктындагы 3 пунктчасының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::
«Функциональ карау җайланманың төзеклеген һәм тотрыклылыгын тикшерү, җайланма конструкциясе элементларының тузганлыгын ачыклау максатында җентекле караудан гыйбарәт. Тикшерүне өч айга бер тапкыр җитештерүче инструкциясе нигезендә үткәрәләр. Җиһазларның яшерен, авыр үтеп керә торган элементларына аерым игътибар бирәләр.»
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм

мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталындагы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләмавыл җирлеге башлыгы Г.В.Кубашева